
# «Китап алсаң кулыңа, нур сибелер юлыңа»



Бар минем дускаем,
Иң якын сердәшем,
Һәр җирдә, һәр эштә
Киңәшчем, иптәшем.
Өйрәтә ул миңа
Бар фәнне, телләрне.
Юк  аның белмәгән
Сәнгате, һөнәре.
Син аны беләмсең?
Кем соң ул? Уйлап тап!
Иң якын дускаем,
Киңәшчем, ул - ….Китап.
Җ.Тәрҗеманов



# Табышмаклар.

- 1. Ак җирдә кара тап. Нәрсә булыр , уйлап тап .
- 2. Анда бар да бар.
- 3. Теле юк - үзе аңлата.
- 4. Юк аягы , юк күзе . Сөйли , аңлата үзе . Телгә аннан оста юк, аннан якын дус та юк.

# Мәкальләр.

- Уку кешене күзле итә .
- Гыйлем байлыктан яхшырак .
- Алтын җирдән табыла , акыл – китаптан.
- Китап галим, телсез мөгаллим
- Китап ул- белем чишмәсе.